Тема : Мәнге үлмәячәк якты хыяллар (Ә.Еники хикәяләрендә Бөек Ватан сугышы темасы)

Максат : 1.Халык язучысы Ә Еникинен тормыш юлы,иҗатына күзәтү ясау; дошманны җиңүгә омтылышның язучы хикәяләрендә чагылуы.

2.Бәйләнешле сөйләм телен үстерү,мөстәкыль фикер йөртү күнекмәсен арттыру.

3.Бөек ВЫатан сугышы ветераннарына ихтирам,хөрмәт тәрбияләү.

Җиһазлау : язучының портреты,китапларыннан күргәзмә,эпиграф язылган плакат,сораулар язылган карточкалар,презентация,саннар язылган карточкалар,төркемнәргә бирү өчен таблица,сүз төзү өчехәрефләр,сәхнәләштерү өчен кирәкле әйберләр.

Материал : 1. Ә.Еники.Сайланма әсәрләр.Казан : ТР "Хәтер" нәшрияты (ТаРих),2002

2.Ә.Еники.Әсәрләр.Өч томда.III том.Хикәяләр.Казан.Татарстан китап нәшрияты.

3.Ә.Еники .Хикәя турында.Язучылык хезмәте турында.-Казан : Татарстан китап нәшрияте,1965 ел

4.Ганиева Ф.Ә. Әдәбият – ул сүз сәнгате.Казан утлары.-1983 №9

5.Хатипов Ф. "Әдәбият теориясе"-Казан : Раннур,2002

Планлаштырылган нәтиҗәләр :

Метапредмет-укыганны гомумиләштерә,нәтиҗә ясый ,мөһим мәгълүматны аера белү.

Предмет – язучы иҗаты турындагы белемнәрне камилләштерү,язучының хикәяләре белән танышу

Шәхси- укучылар белән сугышның төрле афәтләр ,ачлык,бәла-казалар,үлем-җитем,күз яшьләре,җимереклекләр,аерылышулар алып килүе турында сөйләшү.

Дәрес барышы

I . Оештыру өлеше

Дәрескә хәзерлекне тикшерү.Уңай психологик халәт тудыру.Бер-беребезгә күтәренке кәеф,яхшы эш көне теләп,язгы,кояшлы матур иртәдә дәресебезне башлап җибәрәбез.

II. Укучылар,без үткән дәрестә Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнә башладык.Ә.Еники – татар әдәбиятын күп төрле әдәби типлар,тормышчан образлар белән баеткан язучы.Аларда әдип үз заманы героеның катлаулы язмышын, каршылыклы характерларын күрсәтә.Әдипнең иҗат дөньясы киң һәм күпкырлы.Аның әсәрләрендә сүрәтләнгән кеше образлары тирән эчке кичереш,сиземләү кебек катлаулы психологик халәтне бирү ярдәмендә ачыла.Язучы һәр укучыны да шатландыра,уйландыра торган әсәрләр яза.Алар озын гомерле.Язучының иҗатында йөзек кашы булырдай бер генә әсәрне дә аерып алырлык түгел.Алар һәммәсе дә берсеннән-берсе матуррак мәрҗәннәрне хәтерләтә.

Күренекле шагыйрь Илдар Юзеев Әмирхан аганы “Күңел карурманнарының тургае” дип атады.Менә без бүгенге дәресебезнең эпиграфы итеп шушы җөмләне алдык.Ни өчен И.Юзеев аңа шундый бәя биргән?

Көтелгән җавап : Чөнки язучы кешеләрнең күңел кичерешләрен,серләрен бик оста итеп,бөтен нечкәлекләре белән сурәтли.

2.Өй эшен тикшерү.Ә.Еникинең тормыш юлына,иҗатына кагылышлы сорауларга җавап бирү.Һәр укучыга 1 сорау.Сорауга тиз генә җавап бирсә,1 балл,җавап бирә алмаса 0 балл куела.Җавап бирү өчен 3 секунд вакыт бирелә. (Дәрес дәвамында алган баллар тактадагы таблицага куелып барыла.Таблицада укучыларның исем-фамилиясе һәм дәрестә эшләнәчәк эш төрләре языла.Дәрес ахырында шуңа карап билге куела)

| Укучының исеме | Өй эше | Төркемдә эш.Хикәяләргә анализ. | Сорау-җавап | Өзекне таны | Йолдызлы сәгать | Хатаны тап | Таблица | Балл |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Алсу | | | | | | | | |
| Диләрә | | | | | | | | |
| Азат | | | | | | | | |
| Алисә | | | | | | | | |
| Илсаф | | | | | | | | |
| Нуршат | | | | | | | | |
| Салих | | | | | | | | |
| Солтан | | | | | | | | |
| Кәримә | | | | | | | | |
| Самирә | | | | | | | | |
| Айзилә | | | | | | | | |
| Динислам | | | | | | | | |

1.Ә.Еники туган ел ел? (1990  ел 2 март)

2.Ул туган авыл? (Иске Айман)

3.Кайсы әсәрендә С.Сәйдәшев образы сурәтләнә?(“Гөләндәм туташ хатирәсе”)

4.Кайсы җыентыгы өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде?(“Юлчы”)

5.Сез укыган әсәрнең исеме ничек?(“Әйтелмәгән васыять”)

6.Аның исеме матбугатта ничәнче елларда күренә башлый? (1926)

7.Ә.Еникинең “дөньяга күзе ачылган урын” дип кайсы авылны атыйлар? (Дәүләкән)

8.Язучылар белән беренче очрашуына нәрсә сәбәп була?(алар авылна кымыз эчәргә киләлр)

9.Казанга килгәч,ниндиэшкә урнаша?(китап кибетенә курьер булып )

10.Беренче язылган повесте?(“Рәхмәт,иптәшләр”)

11.”Рәшә” повестенең төп герое? (Зөфәр)

12.Аның таланты чын мәгънәсендә кайсы елларда ачылып китә? (Бөек Ватан сугышы елларында)

Нәтиҗә ясау.Өй эше өчен балл кую

III.Яңа тема аңлату

-Укучылар,соңгы сорау нәрсә турында иде?

Көтелгән җавап : Ә.Еникинең таланты Бөек Ватан сугышы елларында ачыла.

Димәк,бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр?Дәрестә ни белән шөгыльләнербез?

Көтелгән җавап: Бөек Ватан сугышы темасының язучы иҗатында ничек чагылдырылуы турында сөйләшербез.

Сугыш,ул китергән авырлыклар турында презентация (Презентация буенча алдан әзерләнгән укучы чыгыш ясый)

- Укучылар,Ә.Еники язмышы да ил күләмендәге тарихи вакыйгалардан аерылгысыз.1941 нче елда башланып киткән,бөтен җиһанны үзенә тартып алган сугыш хәрәкәтләре әдипне дә читләтеп узмый.Бу елларда ул үзенең нинди хикәяләрен иҗат итә?

Көтелгән җавап : “Бала”,”Ялгыз каз”,”Ана һәм кыз”,”Бер генә сәгатькә”,”Кем җырлады?” хикәяләрен һәм “Мәк чәчәкге” нәсерен иҗат итә.

Бу әсәрләрендә ул сугышны сурәтләүне максат итеп куймый.Сугышта катнашкан кешеләрнең эчке кичерешләрен сурәтләүгә зур урын бирә.Бу хикәяләр аңа иҗатка олы юл ача : ул язучылар берлегенә кабул ителә һәм әсәрләре аерым китап итеп бастырыла.

Бу дәрестә без 4 төркемдә эшләрбез.Һәр төркем үзенә тиешле хикәяне укып килде.

1 төркем “Бала” хикәясе

2 төркем “Ана һәм кыз” хикәясе

3 төркем “Бер генә сәгатькә” хикәясе

4 төркем “Ялгыз каз” хикәясе

Хәзер сүзне 1 төркемгә бирәбез.Башкалар сөйләгәндә калганнар таблица тутырып бара. Әзер таблица бирелә. (Һәр төркемгә бер).Төркемнәргә чыгыш ясау өчен 5 минут вакыт бирелә.

| Әсәрнең исеме | Жанры | Төп герой | Күтәрелгән проблема | Идеясе |
|---|---|---|---|---|
| “Бала” | | | | |
| “Ана һәм кыз” | | | | |
| “Бер генә сәгатькә” | | | | |
| “Ялгыз каз” | | | | |

1 төркем- “Бала”хикәясе

1 укучы-кыскача эчтәлеге белән таныштыра

2 укучы- әсәрнең жанры,идеясе,күтәрелгән проблема белән таныштырып китә.

3 укучы кеше кайгысына битараф булмаучы,башкаларга ярдәм итүче сыйфатларына ия булучылар турында сөйли.

Алдан әзерләнгән 2 укучы Зариф белән командирының сөйләшүен сәхнәләштереп күрсәтә.

2 төркем- “Ана һәм кыз”хикәясе

1 укучы-кыскача эчтәлеге белән таныштыра

2 укучы- әсәрнең жанры,идеясе,күтәрелгән проблема белән таныштырып китә.

3 укучы зур кайгы кичерүчеләр ,аны сабыр гына үткәреп җибәрүчеләр турында сөйли.

Алдан әзерләнгән 2 укучы Рәхилә белән апасы Хәлимәнең сөйләшүен сәхнәләштереп күрсәтә.

Ял итеп алу.Татар бию көенә хәрәкәтләр күрсәтү.

3 төркем- “Бер генә сәгатькә”хикәясе

1 укучы-кыскача эчтәлеге белән таныштыра

2 укучы- әсәрнең жанры,идеясе,күтәрелгән проблема белән таныштырып китә.

3 укучы –аерылышу фаҗигасе турында сөйләшү

Алдан әзерләнгән 3 укучы Гомәрнең өйгә кайтып кергән вакытын сәхнәләштереп күрсәтә.

4 төркем- “Ялгыз каз”хикәясе

1 укучы-кыскача эчтәлеге белән таныштыра

2 укучы- әсәрнең жанры,идеясе,күтәрелгән проблема белән таныштырып китә.

3 укучы тыныч тормыш шартларында гына очраучы казның тынычлыкны символлаштыручы кош булуы турында сөйли

Алдан әзерләнгән 2 укучы Иван поварның каз белән “сөйләшүен”сәхнәләштереп күрсәтә.

Нәтиҗә ясау.Төркемдәгеләр бер-берсенең эшенә бәя бирә.Эшләр 5 балл белән бәяләнә.

IV.Ныгыту.

**1.Хикәяләрне укыганда , игътибарлы булдыгызмы икән?Һәр укучыга 1 сорау.Җавап бирә алса,1 балл куела.**

1.Әбиләргә кунакка баручы герой кайсы хикәядән?(“Бала”)

2.Солдатларда кызыксыну тудыырган,авылда сакланып калган могҗиза?(каз)

3.Кайсы хикәядә ананың 3 улы да сугышка китә?(“Бер генә сәгатькә”)

4.Немецлар киткәннән соң бу авылга тәэминат ротасы килеп урнаша.(“Ялгыз каз”)

5.”Юкка күзләренә күрендем”,-дип уйлаучы кем ул,кайсы хикәядән?(“Бер генә сәгатькә”дә Гомәр)

6.Кайсы хикәядә геройның колагына кайдадыр якында гына ашлык суккан машинаның гөрләве,эре көлтәләрне тартып алып йоткан чакта үкереп куюы ишетелгән кебек була?(“Бала”)

7.Былтыр институтны тәмамлап кайтырга тиешле егет (“Ана һәм кыз”)

8.Бердәнбер улының фронттан кайтуын көтүче ана. (“Ана һәм кыз”)

9.Итекче,повар,тегүче кайсы хикәя геройлары.(“Ялгыз каз”)

10.10 яшьлек Зәйнәп кайсы хикәя герое? (“Бер генә сәгатькә”)

11.Кулына берничә бөртек каен җиләге учлаган герой кайсы хикәядән? (“Бала”)

12.Кайгысы зур булса да,елый алмаучы кыз?(“Ана һәм кыз”)

**2.Менә сез иптәшләрегез сөйләгәнне тыңлап утырдыгызмы икән,шуны тикшереп карарбыз.Һәр төркемгә үзе сөйләмәгән хикәядән өзек бирелә.Укып,кайсы хикәядән икәнен әйтергә.Тиз генә җавап бирә алса,1 балл куела.**

1 төркем.”Тыныч җан белән үлемне көткән бу авыру анада соңгы сулышыннан аерылу минутын кичектерү теләге бик көчле : ул улын көтә.Бердәнбер улының фронттан кайтуын ,менә шул кечкенә ишектән иелә төшеп керүен,елмаеп янына килүен,”Әни!” дип дәшүен күрергә тели иде”.(“Ана һәм кыз”)

2.”Юл ат,арба,машина эзләре белән тулы.Бу юл – бүгенге мәхшәрнең бердәнбер телсез шаһите.Ике туганнын бер үк эзгә басканын бер ул гына белә.Ә шулай да ул бу сәгатьтә нинди мәкерле,тыныч һәм нинди буш” (“Бала”)

3.”Бу туйда берәү дә ялгыз түгел,һәр җан иясенең эше бар.Һәр җан иясе ана була,бала үстерә.Әнә кайбер кешеләр инде симез кортларны сыртларыннан тешләп ояларында чыр-чу килгән зур авызлы,ялангач башлычебиләренә ташыйлар.(“Ялгыз каз”)

4.Чәй урынын җыештырып бетерүгә,мич буендагы сандык өстенә менеп,аркасын мичкә терәп, бөрешеп ятты.Күпме-азмы ятканнан соң,ул йокыга талган кебек булды.(“Бер генә сәгатькә”)

**3.Экранда әсәр исемнәре язылды.Сорау укыла,тиешле номер язылган карточканы күтәрергә.Җаваплары дөрес укучыларга 1 балл куела.**

1. “Бер генә сәгатькә”
2. “Ялгыз каз”
3. “Ана һәм кыз”
4. “Бала”

1.Сәлимов фамилияле кеше кайсы әсәрдән? “Бер генә сәгатькә”

2.Кайсы хикәя 1941 нче елда язылa? “Бала”

3.Кайсы хикәянең төп героe Хәсән? “Ана һәм кыз”

4”Баллада о солдате”дигән рус совет фильмы белән аваздаш әсәр? “Бер генә сәгатькә”

5.1944 елда язылган әсәр? “Ялгыз каз”

6.Кара киемле ябык рус хатыны кайсы хикәядән? (“Бала”)

7.Беренче мәртәбә сугышка керүче герой? (“Бала”)

4.Хаталы җөмләләрне төзәт.Һәр укучыга 1 сорау.Җавап бирсә,1 балл куела.

1.Лейтенант Иванов ротасы авыл эче (дөрес җавап урман эче) буйлап зур саклык белән алгы позициягә китеп бара.

2.Бабай (Ана) күптәннән каты авыру һәм ул бу урынга инде яңадан тормаска ятканлыгын яхшы белә.

3.Рәхилә , ишектән чыгуга, чак кына апасы Халидә (Хәлимә) белән бәрелешмәде.аб

4.Машаның ире үлгән (фронтта) ,ә җитеп килгән бердәнбер кызы шәһәрдә эштә иде.

5.Зарифның да өч яшьлек Фәниләсе (Фәридәсе) бар.

6.Ир (хатын) ,баласын күтәргән килеш, аның артыннан омтылып нәрсәдер кычкырды.

7.Карты белән киленен эшкә озаткач,Мәликә (Мәрьям) абыстай иренеп кенә чәй урынын җыештырырга кереште.

8.Иван тегүче (повар) ала казның кинәт болай үзгәреп китүен берничек тә төшендерә алмады.

9.Зариф этне (баланы) кысып тоткан килеш,аяк астында аунаган чыбыкларга,агач төпләренә абынмас өчен сикерә-атлый ,ашыгып юлга чыкты.

10.Шушы минутта Рәхилә күрше хатыны (почта таратучы) Маһирәнең тәрәзә каршысыннан үткәнен күреп алды.

11.Мәрьям абыстай исә,бичара,иренең (Гомәрнең) һәр сүзен,һәр карашын,һәр хәрәкәтен күз алдыннан һич югалтмаска тырыша.

12.Заһидә күршесе (сөйгәне) Гомәрне күрми калуның никадәр үкенечле булуы турында да юньләп уйламый иде.

V. Рефлекция

Бирелгән хәрефләрдән сүз төзергә .(Һәр төркемгә 1 сүз)

1т- Тырышлар

2 т – Белемлеләр

3 т – Сәләтлеләр

4 т – Уңганнар

Димәк,сез бүген дәрестә үзегезнең нинди сыйфатларыгызны күрсәтә алдыгыз?

Көтелгән җавап : Без тырыш,белемле,сәләтле,уңган булуыбызны күрсәтә алдык.

Дәрестә нәрсә эшләргә тиеш идек?Нәрсә эшләдек?Нинди нәтиҗәгә килдек?

VI. Үзбәя.Актив катнашкан укучыларны билгеләп үтү.Тутырылган таблицаларга бәя бирү.Җыелган баллга карап билге кую.

VII. Өй эше бирү.”Мәк чәчәге” нәсерен укып килергә.Төркемнәргә презентацияләр эшләргә тәкъдим итү.

1т-Безнең авылыбызның сугыш ветераннары

2т-Безнең авылыбызның тыл ветераннары

3т-Авылга сугыштан килгән хатлар

4т-Сугыш һәм тыл ветераннарын хөрмәтләү